Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LII-2**

Балык Бистәсе штп. 2024 елның 26 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетын норматив-хокукый яктан җайга салуы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы өстендә кала торган җирлек территориясен төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру органы итеп билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары белән төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу торган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзергә һәм күрсәтелгән килешүләрне закон таләпләре нигезендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирлекләре бюджетларыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла, шулай ук

Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үзенең матди ресурсларын һәм финанс средстволарын файдаланырга хокуклы.

5. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов